ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ЧЕТЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 56/1

Чистай муниципаль районы
Четырчы авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Четырчы авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Четырчы авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 55/1 номерлы карары, Четырчы авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 14 номерлы карары белән, Четырчы муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Четырчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

1)“Сез Чистай муниципаль районы Четырчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1нче төркем инвалидлардан кала, 2019 елда 150 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы:

- Четырчы авылы эчке сууткәргеч челтәренә ремонт ясауга;

ӘЙЕ ЮК”.

*2)* Сез 2018елда кертелгән мәсьәлә буенча: зират өчен җир участогы рәсмиләштерүгә документлар әзерләү, төзекләндерү, тотып алу һ.б.( 1000 сум

халыктан җыелган акча, 4000 сум Республикадан күчкән акча) җыелганнан калган салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы :

Четырчы авылында эчке суүткәргеч челтәренә ремонт ясауга

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Четырчы авыл җирлеге
башлыгы М.В.Новиков